ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

21.09.2015 — с. Русское Макулово — 5

Гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Макыл авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Карар бирәм:

1. Кадастр номеры 16:15:110104:170, гомуми мәйданы 162 кв. м булган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздырырга.
2. Рус Макылы авылы, Үзәк урамы, 125 йорт адресы буенча Макыл авыл мәдәният йорты халык алдында тыңлаулар үткәрү урыны итеп билгеләргә. Үткәрү датасы - 2015 елның 1 октябре, үткәрү вакыты - 14.00.

Кадастр номеры 16:15:110104:170 булган, гомуми мәйданы 162 кв.м. булган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Рус Макыл авылы, Үзәк урамы, 110 йорт.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы

А. И. Матвеева